Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Байлангар авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 март, 2024 ел № 10

Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы Сазтамак авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Байлангар авыл җирлеге Уставы нигезендә, Байлангар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 04 апрелендә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Сазтамак авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы,16а адресында урнашкан Сазтамак мәчете бинасында үткәрергә.
2. 2024 елның 04 апрелендә 17 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 2 номерлы Сазтамак авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы,16а адресында урнашкан Сазтамак мәчете бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Сазтамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түбәндәгеләрдән тыш:
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары
2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм койма тоту, ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;

- урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- Сазтамак авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазландыру, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

- юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- Сазтамак авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре;

- Сазтамак авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскыч урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре;

2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

**- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Сазтамак авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскыч урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Сазтамак авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре); (юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (Сазтамак авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре), (спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

**- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү** зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал

сатып алу койма тоту һәм ремонтлау , инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Байлангар авыл җирлеге башлыгы: Кәримуллин И.Ф.